Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XXV-4**

Балык Бистәсе штп. 2017 елның 28 декабре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына керә торган мөрәҗәгатьләрне карау эше нәтиҗәләре турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына керә торган мөрәҗәгатьләрне карау эше нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппараты җитәкчесе Р.Д. Исмәгыйлев мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына керә торган мөрәҗәгатьләрне карау эше нәтиҗәләре турында мәглүматны игътибарга алырга.

2. Җаваплы затларга тәкъдим итәргә:

«Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына керә торган мөрәҗәгатьләрне карау буенча эшне дәвам итәргә;

бүгенге көндә «планлаштырылган» стадиясендә булган гаризалар буенча билгеләнгән срокта конкрет карарлар кабул итәргә;

массакүләм мәгълүмат чараларында «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы эшен актив яктыртырга.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе вазыйфаларын башкаручы И.Г.Ибраһимов